Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге Советы
КАРАРы

**«31» январь 2022 ел** **№ 45**

**"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең генераль планын әзерләү зарурлыгы булмау турында»**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясеннән гамәлдәге файдалануны үзгәртү күздә тотылмавын, Татарстан Республикасы һәм Кама Тамагы муниципаль районының территориаль планлаштыру схемалары белән расланган комплекслы социаль-икътисадый үсеш программасы булмавын һәм федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең генераль планын 2025 елның 31 декабренә кадәр эшләү зарурлыгы булмавын таныргa.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 31 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш
авыл җирлеге башлыгы,
Иске Барыш авыл җирлеге Советы рәисе И.Р.Җиһаншин